СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 322 от 25.11.2019
на № __от _________

# К А Р А Р

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә
беренчел хәрби исәпкә алуны башкару
буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл
җирлекләре бюджетларына субвенцияләр
бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 ел бюджетыннан башлап һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Р. Р. Закирҗанов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының 2019 елның
25 ноябрендә кабул ителгән
322 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләре**

1. Әлеге кагыйдәләр, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр).
2. Субвенцияләр җирлекләр бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында бирелә.
3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан субвенция тора.
4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының җаваплы оештыручысы булып Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тора (алга таба – Башкарма комитет).
5. Җирлек бюджетына субвенция күләме, “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”гы 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Законга 1 кушымта нигезендә, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен муниципаль район

бюджетыннан җирлек бюджетына субвенция күләмен ачыклау Методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Саба муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Саба муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр җирлекләр бюджетларына түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен бирелә:

– хезмәткә түләү фондына тиешле исәпләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;
– биналар арендасы өчен түләү;
– элемтә хезмәтләре өчен түләү;
– транспорт хезмәтләре өчен түләү;
– командировка чыгымнары;
– коммуналь хезмәтләр өчен түләү;
– җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе (алга таба - Казначейство) территориаль органнарының, җирлекләр бюджетларын үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган шәхси счетлары аша гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитет, казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң, җиде эш көне эчендә, Казначылыкка, субвенцияләр хисабына, җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләр бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килешү буенча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Башкарма комитетка тапшыралар.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет

кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты keременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.